**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Югары Чура авыл җирлеге башлыгы**
**карары**

**2023 елның 14 ноябре** **№ 9**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 30 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Югары Чура авылы, Мәктәп урамы, 1 йорты адресы буенча урнашкан мэктэп бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 30 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Югары Чура авылы, Мәктәп урамы, 1 йорты адресы буенча урнашкан мэктэп бинасында үткәрергә.

3. 2023 елның 30 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Чура авылы, Мәктәп урамы, 1 йорты адресы буенча урнашкан мэктэп бинасында үткәрергә.

4 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы

Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Чура авылы урамы юлларына вак таш җәю һәм юлларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары-Чура авылы урамнарында, вак таш җәеп, юлларда чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су башняларын, су саклау зоналарын карап тоту, Югары-Чура авылын су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;

- Югары-Чура авылының автомобиль юлын (переход) ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары-Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы-машинист хезмәте күрсәтү;

- Югары-Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү;

- Югары-Чура авылына видеокамералар һәм видеокүзәтү системалары сатып алу һәм урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;

- Югары-Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары-Чура авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;

- Югары-Чура авылында юлларга асфальт салу һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы: В.Н. Андреев